## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
## (IV чакырылыш)

## КАРАР

IV чакырылыш чираттан тыш утырышы

17 февраль, 2021 ел №34 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2016 елның 24 декабрендәге №47 "Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында" карарына үзгәрешләр кертү турында

Инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, предприятиеләргә һәм оешмаларга ярдәм итү, җитештерүне, сәнәгатьне үстерү, Ютазы муниципаль районы территориясендә эш урыннарын арттыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә капитал салулар рәвешендә гамәлгә ашырыла торган инвестиция эшчәнлеге турында» 1999 елның 25 февралендәге 39-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 гыйнварындагы №1872 Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1999 ел, 7 май, №284 карары, шулай ук «Ютазы муниципаль районында инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү тәртибе турында» гы Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 29.07.2011 ел, № 29 карары белән расланган Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Ютазы районында сәнәгать паркы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыручы предприятиеләргә һәм оешмаларга муниципаль ярдәм күрсәтү турында» 2018 елның 24 декабрендәге №47 Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта “2019-2020 елларга” саннарын һәм сүзен “2021 елга” саны һәм сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы инвестиция проектын гамәлгә ашыру турында шартнамә шартларын бозган вакыттан туктатыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында “Рәсми Татарстан” дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы Ютазы
районы Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин